# 1 МАЙ - ЯЗ, ТЫНЫЧЛЫК, ХЕЗМӘТ БӘЙРӘМЕ!


СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

30 апрель, 1997 ел.
ЧӘРШӘМБЕ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 47 (8059) | Бәясе билгеләнгәнчә


## Кырда хезмәт гөрләп барса, өстәлдә икмәк булыр

### «Чәчү - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

**Утырып киткән көннәр язгы кыр эшләренең темпын кискен арттырырга мөмкинлек бирде. Әйтик, уҗым культураларының тырмаланган һәм ашлама белән тамырдан тукландырылган мәйданнары ике мең ярым гектардан күбрәк булган икән, шуның яртысыннан артыгы - тулы бер көндә башкарылган эш. Туңга сөрелгән җирләрдә дым каплату белән дә шундый ук хәл: барлык мәйданның өчтән берендә диярлек үткәрелгән бу эшнең яртысына якыны - соңгы бер көннеке. Киекле, Муса Җәлил исемендәге, «Рассвет», «Кондырча» хуҗалыкларында бу мөһим агрочара барлык мәйданның яртысыннан күбрәгендә башкарылган инде. Ә менә «Восход», «Игенче», «Правда» һәм кайбер башка хуҗалыкларда дым каплату эше темпы түбән әле.**

**Күпьеллык үләннәрне тамырдан тукландыру һәм тырмалау кебек мөһим агрочараны Киекле, «Восход», Муса Җәлил исемендәге, «Родина», «Комбайн», «Татарстан», Әлмәт КХАларында беренчеләрдән булып тәмамладылар. Ә менә «Правда», «Төрнәс», Кузнецов исемендәге һәм кайбер башка хуҗалыкларда бу эш тизләтүне сорый.**

**Уҗымнарны тукландыру «Кондырча», «Рассвет», «Сөлчә», Киекле хуҗалыкларында барлык мәйданның яртысыннан артыгында башкарылган бер вакытта кичәге көнгә ул эшкә керешмәгән хуҗалыклар да бар иде әле.**

**Ә бит инде төп эш - сабан культуралары чәчүдә чынлап торып керешүне сорый. Мичурин исемендәге, Киекле, Якты Күл һәм кайбер башка хуҗалыкларда бодай һәм арпа чәчелгән мәйданнар ишәя бара инде.**

### Алдынгыларга - тигезләнегез

***Районда язгы кыр эшләре киң колач алып килә. Инде кайбер хуҗалыкларда яхшы күрсәткечләр белән эшләүче кыр батырлары да мәгълүм.***

«Алга» КХАсыннан **ШӘҮКӘТ СОЛТАНОВИЧ МИНДУБАЕВ** Т - 70 тракторы белән дым каплатуда көнлек нормасын 229 процентка үтәде.

Мичурин исемендәге КХАдан **ДМИТРИЙ ЯКОВЛЕВИЧ ЯРГУНОВ** дым каплатуда көнлек нормасын 200 процентка үтәде. Ул эш башыннан бирле 115 гектар җирдә дым каплаткан.

Шикәр заводының «Восход» ярдәмче хуҗалыгыннан **ФЕДОР НИКОЛАЕВИЧ ИВАНОВ** Т - 4 тракторында күпьеллык үләннәрне тырмалауда нормасын 176 процентка үтәде. Ул тырмалаган җирләр 125 гектарны тәшкил итә.

### Майда ничек ял итәбез?

***Май башында өч көн рәттән - 1, 2, 3се ял итәбез һәм 4се (якшәмбе) көнне җомга көн өчен эшлибез. 9 нчы май - Җиңү бәйрәме җомга көнгә туры килгәнлектән, тагын өч көн рәттән - 9, 10, 11е ял ителә.***

## ИРТӘ ӨЛГЕРГӘН - ОТКАН

Соңгы көннәрдә бозылып киткән һава җиң сызганып эшкә керешкән түбән норлатлыларның кулына суккандай булды. Юкса, дым каплату, кырларны тукландыру эшләрен күптән төгәлләр җайлары бар иде. Рафик Гомәров, Әсгать Тәмаев, Әнвәр Вәлиев аңа беренче көннәрдән үк бик әйбәт керешеп киткәннәр иде, эш ике сменада оештырылды. Эшнең 10 - 15 проценты гына калгач, тәмамланмаган участокларга карап көеп утыруны авыр кичерделәр алар. Шуңа көн ачылуга басуга юнәлделәр. Җирләрне өстәмә тукландыру белән мәшгуль Фәрит Абдуллин, Идрис Хөсәенов, Насыйх Ибәтуллин да аяз көнгә куанып кырга ашыктылар. Егетләр 335 гектар җиргә өстәмә сый бирделәр. Гомумән, чәчү башыннан бирле тик тормыйлар алар. Идрис 65 гектарда уҗымны өстәмә чәчеп өлгерде, аның артыннан ук Хафиз Халитов участокны тырмалап чыкты. Күпьеллык үләннәрне тамырдан тукландыруда Фәрит Газизов шулай ук тынгы белмичә эшләп килә. Шулай бүген тизрәк дым каплату, тукландыру эшләрен төгәлләп төп мәшәкать - чәчүгә керешергә әзерләнеп йөриләр игенчеләр. Рафик Мәүлетович Гомәровны без нәкъ бодай чәчеләсе участокны ВНИИССР белән тигезләгәндә очраттык. 32 нче язын басуда каршылый икән инде ул, нигездә Т - 4 кебек чылбырлы тракторларда эшләгән. Киң алынлы яңа культиватор белән эшләүне аңа ышанып тапшырулары да аңа аерата хөрмәт билгесе бит. Бүген башкара торган хезмәте дә бит таныш. Аның артыннан ук Фәрит Абдуллин агрегаты бодай чәчәргә керешәчәк. Быел Түбән Норлат бригадасында 280 гектар сабан бодае чәчү күздә тотыла. «Люба» сортлысын үстерергә җыеналар, орлык сыйфатлы, ашлама белән чәчәчәкләр. Агроном Әсгать Куләев әйтүенчә, бригадада ашлама быел бик күп - һәр гектарга 205 килограмм тәэсир итүчән матдә исәбеннән тупланган. Аны дөрес итеп уңышка хезмәт итәргә кертәсе генә кала. Анысы да уйланылган. Ашлама, ашлык төягечләре 2шәр, шуның ярдәмендә төгәл технология нигезендә эшләргә җыеналар хуҗалыкта.

- 193 тонна өстәмә сый керде инде кырларга,- ди бүлекчә управляющие Ф.Хөсәенов бу хакта.

Әлбәттә, бодай чәчү - аркылыга - буйга, технологик колея калдырылып башкарылачак. Бодай артыннан ук чиратта - кукуруз, борчак чәчү тора. Беренчесен 160 гектарда бөртеккә, 215 гектарда силоска игәргә җыеналар. Бу - Ислам Галәветдинов биләмәләре. Ул анда кулдашы Насыйх Ибәтуллин белән бар эшне дә үзе башкарачак. Борчакка килгәндә, аны быел силос максатларында 80 гектарда аерым да чәчәчәкләр.



Билгеле инде, чөгендер басуына аерата игътибар хуҗалыкта. Аны күздән сөреп, тигезләп ашлама кертеп калдырдылар. Хәзер анда гербицид сиптерәләр. Ә чөгендер игү звенолары җитәкчеләре Әсгать Тәмаев, Әнвәр Вәлиевка аннан калган хезмәтне күрсәтәсе, боерык бирәсе юк.

Шулай һәр җирдә хәрәкәт бүген. Иң мөһиме, кырдагы күрсәткечләрне игенчеләр үзләре дә, авыл халкы да көннекен көнгә белеп тора. Авылда 4 җиргә - идарә бинасына да, мастерскойга да, хәтта кибет янына да көнлек күрсәткечләр эленеп тора. Кырда хезмәт күрсәтүдә дә өзеклек юк. Шефлары - НУЭООС чәчү чорына биргән 3 тракторга да басуда эш табылган.

- Халыкта теләк зур, көннәр әйбәт торганда, чәчүне озакка сузмабыз,- ди агроном Ә.Куләев.

Шулай, иртә өлгергән - иң откан. «Кондырча» КХАсының Түбән Норлат бригадасы моңа инанып өлгерделәр инде.

**С.ХӘЙРУЛЛИНА.**

**Рәсемдә: механизатор Р.М.Гомәров.**

## Районга Президент килде

**29 апрельдә районыбызга Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәрип улы Шәймиев килде.**

**Район хезмәт ияләре, бар халык мөхтәрәм Президентыбызны Норлат җирендә эчкерсез сәламлыйлар, аңа исәнлек, күңел көрлеге, хөкүмәт эшләрендә нәтиҗәле уңышлар телиләр.**

**М.Ш.Шәймиевның районда булуы турында отчет газетабызның киләсе санында биреләчәк.**

### Районыбыз тормышыннан хәбәрләр

## ӨМӘГӘ ЧЫКТЫК

**Норлат нефтьчеләре** гомумшәһәр өмәләреннән читтә калганнары юк әлегә. Шулай, үткән шимбәдә дә эшчеләр, инженер - техник хезмәткәрләр һәм «Норлатнефть» НГДУсының башка хезмәткәрләре берничә сәгать дәвамында үз тарафларын чистарттылар, юдылар һәм буядылар. НГДУның 21 цехы коллективы эшләгән берничә адресны әйтеп китү дә җитә - производство хезмәт күрсәтү базасы, парафин эреткечен чыгару буенча участок, Советская урамы.

***

Апрельнең беренче яртысында ук **«Норлатнефть» НГДУсының УТТ** коллективы башкалар үрнәгендә үзләренә беркетелгән Карл Маркс урамында язгы чистарту, төзекләндерү эшләрен башкардылар. Аларның тырышлыгы нәтиҗәсендә биредән кыш буе җыелган чүп - чар чыгарылды, агач кәүсәләре агартылды, юл буендагы кое буялды. - Бу урам район үзәгенә алып керә,- диләр транспортчылар,- шуңа да аны тәртиптә тотарга кирәк. «Бу көнне УТТ промбазасы да чистартылды.

***

Районда чисталык айлыгы үткәрелүне **медицина хезмәткәрләре** дә хуплап каршы алдылар. Шулай, табиблар, шәфкать туташлары һәм санитаркалар ак халатларын эш киемнәре белән алмаштырып, 26 апрель көнне район үзәк шифаханәсе территориясен төзекләндерүгә алындылар. Чүп - чарны җыеп түктеләр, биналарны агарттылар, буядылар, поликлиника янындагы газонны коймаладылар. Бу көнне биредә 250ләп каен, чыршы үсентеләре утыртылды - тиздән, җылыткач, яшь яфраклы үсентеләр җилдә тирбәлерләр.

***

Халыкка хезмәт күрсәтүче **«Агропром» һәм саклык банклары** да шәһәрнең әйдәп баручы хезмәт коллективларыннан калышмадылар. Район үзәгендә урнашкан бу биналар игътибарны һичшиксез югары культуралылыклары белән җәлеп итәргә тиеш.

## Бу - сайлаучылар наказы иде

Беренче май бәйрәме алдыннан гына Норлатның төньяк - көнчыгыш ягындагы Шашин поселогында яшәүчеләр әйбәт бүләк алдылар: биредә НГДУ эшчеләрне тәэмин итү бүлеге яңа кибет ачты. Кибеттә ипи, сөт, азык - төлек төсле нәрсәләрдән тыш көндәлек промышленность товарлары да алырга була. Өстәвенә, ул 8дән 19 сәгатькә кадәр ялсыз эшли. Бу кибетне ачу депутатыбыз Хуҗин Марат Мөхлисович тырышлыгы нәтиҗәсендә мөмкин булды. Сайлау алды очрашуы вакытында Норлат - Шашин сайлау участогы сайлаучылары аңа нәкъ шундый наказ биргәннәр иде. Күрәсез, ул биргән вәгъдәсендә торды да. Шуңа да без депутатыбызга һәм НГДУ ОРСы җитәкчелегенә чын күңелдән рәхмәт җиткерәбез.

**Поселок халкы исеменнән - Нажия ФӘТКУЛЛИНА.**

## Алма бакчасы булыр

«Һәр хуҗалыкның иген кыры, чөгендер басуы, бәрәңге бакчасы гына түгел, алма бакчасы да булсын!». Район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллинның бу фикер - тәкъдиме гамәлгә ашырыла башларга охшый. Шушы көннәрдә генә җиләк - җимеш питомнигына район авыл хуҗалыгы идарәсеннән зур заявка керде. Һәр хуҗалыкка 400әр төп исәбеннән алмагач үсентеләре озатырга. Хәзер питомникта шул үсентеләрне әзерләү белән мәшгульләр. Сүз уңаеннан, биредә 4 сортта өчъеллык алмагач үсентеләре бар, алар безнең шартлар өчен бик кулайлар. Хуҗалыкларда алар дөрес тәрбия - карауга юлыксалар, тиздән һәр зур төбәктә алма бакчалары гөрләп үсеп китәрләр дигән ышаныч бар.

Питомникта исә үсентеләрне кисү - өченче кырны формалаштыру да дәвам итә.

### Укучылар игътибарына!

**1, 2, 3 май ял көннәре итеп игълан ителү сәбәпле, «Дуслык» газетасының чираттагы саны сишәмбе, 6 нчы майда чыгачак.**

## *Шәһәребез урамнары*



## А.И.Кузнецов исемендәге урам

Анатолий Иванович Кузнецов 1916 елда Каравыл Тавы авылында туа. Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, Мәскәүдә техникум тәмамлый. Мәктәп скәмиясендә үк авиация турында хыяллана. Очучылар хәзерләүче мәктәпкә комсомол путевкасы алып, үз максатына ирешә ул.

Өч елдан соң авыл егете Кызыл Байраклы Балтыйк флотында иң яхшы очучыларның берсе иде. 1940 нчы елда Анатолий Кузнецов ак финнар белән батырларча көрәшкән өчен Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

Бөек Ватан сугышы елларында Кузнецов 1941 нче елның июненнән бирле сугыша, тагын ике Кызыл Байрак орденнары белән бүләкләнә. Капитан Кузнецов звеносының һава сугышлары һәм штурмнары турында даны бөтен фронт буйлап тарала. Бер ел эчендә 1942 нче елның июненә капитан Кузнецов 270 хәрби очыш ясый, 60 һава һөҗүмендә катнаша, 57 тапкыр фашист гаскәрләрен штурмлый. Ул шәхсән үзе 5 немец самолетын бәреп төшерә һәм иптәшләре белән бергә бәрелешләрдә тагын 8 самолетны юк итә.

Ленинград блокадасын өзү вакытында бәреп төшергән дошман самолетлары саны тагын да арта. 1943 нче елның 19 гыйнварендагы көрәшләрнең берсе вакытында Кузнецов очкычы да түбән мәтәлә. Дуслары командирларының үлеме өчен фашистлардан үч алырга ант итәләр.

СССР Верховный Советы Президиумының 1943 нче елның 22 декабре Указы белән Анатолий Иванович Кузнецовка үлгәннән соң Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

**Рубриканы И.САНДЛЕР алып бара.**

# ЙӨГӘННЕ *бер бушаткач...*

«Комбайн» КХАсының язгы кыр эшләрен быелгыдай хәзерлексез каршылаганнары юк иде әле. Без биредә булган көнне басуда берән - сәрән эшләүче агрегатлар күренсә дә, үзәк мастерской ватык техника белән шыплап тулган иде. Бер көн элек бирегә район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин килеп, бу хәлгә кичекмәстән чара күрүне таләп итмәсә, ул көнне дә мастерскойда эш рәтләп оештырылмаган булыр иде, мөгаен. Район авыл хуҗалыгы идарәсе инженерия хезмәткәрләренә дә район чиге буенда «Комбайн» хуҗалыгы булуын шул визит кына искә төшергән, безнеңчә. Соңлап булса да, алар да ашыгып килеп җитәләр хуҗалыкка. «Сельхозтехника» район берләшмәсенең озак вакыт ремонтчылар кулы тимәгән ике трактор двигателен «Комбайн»га җибәрүләре дә шул гомуми кузгалудан соң гына була. Әмма бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, алар комплектланмаган булып чыга. Көпчәкле Т - 150, ике Т - 70, бер ДТ - 75 двигательләре күздән бирле берләшмәнең алыштыру пунктында ятуын исә бөтенләй онытгылар. ДТ - 75 тракторлары өчен ике арткы күперчек һәм башкалар да бар комбайнлыларның анда. Хуҗалыкның инженерия хезмәткәрләре бирегә күпме генә йөрсәләр дә, һичнинди ярдәм ала алмаганнар. Ул вакытында күрсәтелсә дә, «Комбайн»да хәл бүгенге дәрәҗәдә катлаулы булмас иде.

Хуҗалык шефлардан - ДРСУдан да уңмады. Ашлама, орлык төягеч ясарга вәгъдә биргәннәр иде - оныттылар. Ягулык - майлау материаллары белән дә булышмадылар алар хуҗалыкка. Аларны «уятыр» өчен дә район җитәкчесенең катнашы кирәк булды. Ф.С.Сибагатуллин бирегә килеп киткәч кенә юл төзүчеләр Әмзәгә 20 тонна солярка, 1 тонна май җибәрделәр, тракторлар өчен ике пар чылбыр бирделәр. Ярдәмгә ике трактор килде. Комбайнлыларның кыр эшләрен үз көчләре белән башкарып чыга алмаслыкларын аңлагач, район авыл хуҗалыгы идарәсе СПТУдан ярдәмгә өч трактор җибәрделәр. Ә хуҗалыкның үзенең 8 берәмлек техникасы ремонтта бүген. Аларның барысының да кайчан ремонттан чыгасын да төгәен әйтә алмыйлар. Эш нигездә алда телгә алынган запас частьләр, өлешләр җитешмәүдә.

Газета укучы ялгыш уйлый күрмәсен: «Комбайн»да язгы хәзерлекнең начар булуында комбайнчыларны акларга җыенмыйбыз. Төп гаеп - үзләрендә, безгә калса, соңгы вакытта җитәкчелекнең еш алышынуы тезгенне шактый бушаткан. Механизаторлар отряды да сизелерлек какшаган: 2 - 3 кешедән кала басылып торып эшләүче юк. Механизаторлар арасында хезмәт дисциплинасы түбән, техникага мөнәсәбәт начар. Белгечләр дә үз эшләренә җаваплы карыйлар дип булмый. Мастерской территориясендәге хуҗасызлык та шул хакта сөйли. Һәр кеше үз хезмәт участогы өчен җаваплы булса, еллар буена җыелган металл ватыклары, гамәлдән чыгарылган техниканы гына булса да җыеп кую авыр булмас иде.

Кыскасы, Әмзәдә хәлләр шәптән түгел. Оешмаганлык, бердәмлек булмау, җавапсызлык - нигездә шулар сәбәпче моңа. Юкса, хуҗалык игенчеләренең Әлмәт кустында әйдәп баручыларның берсе булулары да күпләрнең хәтерендә. Халыкның да гомер - гомергә бердәм булып яшәүләре, тырышып эшләүләре мәгълүм. Шуңа да райондагы бердәм күтәрелеш, яңа уңышка нигез салынган бер вакытта Әмзәдәге түбән оешканлык, хуҗасызлык башка сыярлык түгел. Шулай да халыкның бүгенге йомшаруы вакытлыча гына булыр төсле тоела. Һәрхәлдә, күңел шуны тели.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# АЛАР ӨЧЕН ТУГАН ЙОРТ УЛ

Безнен Якты Күл авылында мәктәпкә нигез сигез ел элек салынган иде. Быел, ниһаять, ул ачылды. Бу бәхет безгә урау юллар белән килсә дә, бүген мәктәбебезнең авылыбызга нур чәчеп утыруына чын күңелдән сөенәбез без. 44 укучы биредә рәхәтләнеп белем ала. Без аны файдалануга тапшыруны тизләткән «Якты Күл» хуҗалыгы, җирле үзидарә Советы, район мәгариф бүлеге җитәкчелегенә рәхмәт укыйбыз, шулай ук соңгы эшләрне башкаруда ярдәм иткән ата - аналарга, барлык укытучыларыбызга рәхмәтлебез.

Вакыт үткән саен мәктәбебезне ачу тантанасы кабат күз алдына килә. Авылдашларыбыз көтеп алынган бу вакыйгага зур бүләкләр хәзерләп килгәннәр иде. Авылыбыз мулласы Хатыйп абзый Гайсин мәчет картлары исеменнән мәктәпкә 500 мең сум акча бүләк итте. Шул акчага ике идән паласы алдык. Хәзер нәниләр шунда тәгәрәшеп - тәгәрәшеп күнегүләр ясыйлар. Авылыбызда туып - үскән кешеләр - МПП җитәкчесе Ә.Гайнуллин, ДЮКФП директоры Ф.Гайнуллин, райпода эшләүче Х.Шәрипов бер дигән видеомагнитофон, ОСТО район комитеты җитәкчесе Д.Бикиев зур күләм бүләк иттеләр. Күрше Некрасовка авылы егете, хәзер Чаллы шәһәре эшмәкәре С.Кәбиров балаларны чит илдә эшләнгән телевизор белән сөендерде. Яңа Иглай урта мәктәбе директоры Бикиниев исә мәктәбебезгә бүләк итеп магнитофон алып килде. Бүләкләр укытучыларны да, укучыларны да сөендерде: бүгенге акча кытлыгы заманында аларның һәркайсы мәктәп өчен бик ярап куйдылар. Элеккеге укучыларыбызның мәктәпне тәмамлауларына озак еллар үтүгә карамастан да үзләренә белем нигезләрен биргән мәктәпләрен онытмауларына да сөендек. Шуңа да мәрхәмәтле, олы җанлы бу кешеләргә мәктәп коллективы, укучылар, барлык ата - аналар исеменнән рәхмәт белдерәсем килә.

**Х.САТДАРОВА,**
**мәктәп мөдире.**

## КЫРЛАРДА ҖАНЛЫЛЫК

«Чирмешән» КХАсы кырларында бу көннәрдә җанлылык. Механизаторлар күпъеллык үләннәр тырмалау, тамырдан тукландыру белән мәшгуль. Беренче бригадада бу эш Рифкат Фәсхиев, Әхтәс Рәхмәтуллин, Юныс Фәсхетдиновка йөкләнгән. Егетләр тапшырылган эшне җиренә җиткереп үтиләр. Тиздән бу экипажлар чәчү эшенә керешәчәкләр.

**Җ.Шакиров.**

## Табиблар лицензия белән эшләячәк

Май урталарында район үзәк шифаханәсендә республика лицензияләү - аккредитация комиссиясе эшләячәк. Безнең хәбәрчебез бу хакта аңлатма бирүен үтенеп шифаханәнең баш табибы **З.А.ШАБАЕВКА** мөрәҗәгать итте.

- Лицензия - медицина эшчәнлеге белән шөгыльләнүгә хокук бирүче документ. Табибларыбыз - ә бездә алар хәзер 104 - зачет тапшырып, үзләренең гамәли һәм теоретик белем дәрәҗәләрен күрсәтәчәкләр, кыскасы, үзләрен профессионал буларак яклаячаклар. Түләүле хезмәт күрсәтү белән шөгыльләнергә теләүчеләр дә тиешле документ алырга һәм алга таба, тик салым инспекциясендә теркәлгәннән соң гына, бу практика белән шөгыльләнүләрен дәвам иттерә алачаклар. Табибларның кулында хәзер үз сертификатлары, ягъни шәхси документлары булырга тиеш. Ул 5 елга яраклы була, шуннан соң махсус курсларда белемне камилләштерү шарт. Майда безнең дәвалау учреждениесе үзе дә аккредитацияләнәчәк.

Фотофакт Фотофакт Фотофакт

Фотофакт

# ИСӘПКӘ - БАР, САНГА - ЮК



Язгы чәчү чорына һәр хуҗалыкта орлык һәм ашлама төягечләр булдыру турында сүз күптән, кара көздән башланган иде. Һәм озын кыш буе яз киләсен уйлаган хуҗалыклар РМГ - 6 ашлама ташлагычыннан аны үзгәртеп ясап та куйдылар, кайберләренең шефлары ярдәм күрсәтте. Шулай итеп, чәчү чорына районда 84 ашлык, 57 данә орлык төягеч әзерләнде. Ә бу исә, билгеле, кырда хезмәтне механикалаштырып, вакытны да экономияләргә, югалту - түгелүләрне дә булдырмаска булышлык итә. Һай, һәр җирдә шулай булсачы! Кызганычка каршы, чәчүгә керешүгә, элеккечә үк ашламасын - капчыктан, орлыгын - чиләкләп чәчкечкә тутыручылар бар шул әле. Рәсем - шуңа шаһит. Бу күренешне без «1 нче май» КХАсында арпа чәчкәндә төшереп алдык. Юрий Тихонов агрегаты эшли анда. Әйтүләренә караганда, орлыгы да вакытында килә, ашламасы да. Чәчүчеләр В.Филимонов, М.Васильев, П.Короткин аны шулай кайсын капчык белән, кайсын чиләкләп бушатыпмы бушаталар. Әлбәттә, чәчелә дә, сибелә дә чиләкләп салганда, озакка да сузыла... Ә төягечләре юкмыни?

- Барын бар,- ди хуҗалык агрономы А.А.Герасимов, - тик ул РМГдан түгел, РПТ - 4А10нан ясалган. Аны Т - 150 тракторы белән генә эшләтеп була. Әле кырлар дымлы булганлыктан, трактор кырны тыгызлый - таптый. Шуңа кулдан гына эшләргә булдык.

Һәм, чәчү чорына кырларның шыр коры буласына ният тотканнар, күрәсең.

Иң кызганычы шул: мондый күренеш тагы берничә хуҗалыкта да бар әле. Нәрсә, төягечләр төяргә ярамагач, исәп өчен генә ни дип ясадылар икән соң аны? Әллә буш ислемай шешәсе төсле стенкага куярга гынамы?

Фотофакт

## Объективта үңганнар



Картаймас та икән бу Елена Воспенникова! Яшьтәшләре Лenaның клубта эшләгәнен хәтерлиләр, лаборант вазифасы башкарганын күрделәр. Инде сыер савучы булып эшли башлавына да дистә елга якын, әмма Елена Леонидовнаның йөзе элеккегечә үк мөлаем, кәефе көр. Юкса, гаилә, бала мәшәкате дә басар төсле хатын - кызны. Елена өч бала тәрбияли. Ире терлекләр карый, үзе сыер сава. Өй эшендә дә җитез, фермада да алдынгы ул.

**Рәсемдә: МСОның «Мамык» ярдәмче хуҗалыгы сыер савучысы Е.Воспенникова.**

Н.АЗИЗОВ фотосы.



Андриан Яковлев - шикәр заводының «Восход» ярдәмче хуҗалыгының яшь механизаторларының берсе. Хәрби хезмәткә чакырылганчы ул туган авылы - Андреевкада слесарь булып эшләгән иде. Демобилизацияләнгәч тә читкә китү турында уйламады. Хәзер ул Т - 150 тракторын йөртә. Хуҗалыкта бу төр техника өчен эшнең һичкайчан бетеп торганы юк: терлек азыгы хәзерләүдә, авыл эчендә йөкләр күчерүдә дә кирәге чыга аның. Андриан исә бер генә эштә дә сынатмый.

Бүгенге көндә егет көннәрен мастерскойда үткәрә: барлык механизаторлар белән берлектә ул авыл хуҗалыгы машиналарын агрегатлаштыру белән мәшгуль.

**Рәсемдә: механизатор А.ЯКОВЛЕВ.**

Н.АЗИЗОВ фотосы.

## Базар

# Май, казинаки, хәлвә дә

Норлатка соңгы килүендә Татарстан Республикасы Премьер - министры Ф.Х.Мөхәммәтшин НГДУның көнбагыш мае, олиф һәм буяу җитештерү участогын ошатып китте. «Татнефть»тә бердәнбер булган мондый производство республикадагы тагын бишләп шундый җиһаздан күпкә кулайрак: күләме, шулай ук куәте, экономик файдасы белән дә. Әйе, анысы өчен идарәнең инженерия хезмәте күп көч түкте: технологик циклны безнең шартларга яраклырак, файдалырак итеп нәкъ менә алар җайлаштырды бит. Идарә начальнигы М.М.Хуҗин исә бу эшкә турыдан - туры җитәкчелек итте. Шуңа да район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин беренче тапкыр участокка килгәч тә, кара алтын чыгаручыларның эшен югары бәяләде: базар шартларына ничек кыю яраклашканнар, югыйсә, төп эшләрен генә башкарып ятсалар да берни әйтә алмас идең.

- Тәүлек буе ачык һава астында, нефть - мазутка буялып эшләүчеләрне ашатуны үзебезнең үк бурычыбыз дип саныйбыз,- дигән иде ул вакытта Марат Мөхлисович. Элек көнбагыш маен Краснодардан хәтле кайтартуларын искә алып.

Нефтьчеләрнең көнбагыш мае җитештерә башлауларына өч сезон үтте инде. Елдан - ел остара баралар май җитештерүчеләр. Күрсәткечләре дә яхшыра: рентабльлелек дәрәҗәсенең күтәрелә баруы үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Участок үзебезнең республиканың берничә, Ульян һәм Самара өлкәләреннән җәмгысе 67 хуҗалык белән төзелгән килешү нигезендә кабул итә көнбагышны. Тәүлеккә 10 тонна чимал эшкәртелә. Һәр ике сәгать саен 1 тонна олиф, 8 сәгатьтә 800 килограммлап буяу чыгарыла. НГДУның ихтыяҗларын тулысынча капларга җитә бу. Әле сатарга да кала. Әнә, олифны кибеткә 1 литрын 10.800 сумнан куйганнар иде, күз ачып йомганчы юк булды ул прилавкалардан. Шулай булмый ни: стеллажларны тутырып утыручы олифның ярты литры да 16 мең сум бит. Буяу бәяләре исә байтак очракта ерак - ерак шәһәрләрдән табыштырып кайтартылган компонентлар бәяләренә бәйле булса да, аның һәр килограммының реализацияләү бәясе 13 - 16 мең сумнан артмый. Әнә Югары Норлатта нефтьчеләр буявын ничек ошаттылар. Мәчет, зират тирәләрен кырт иттереп яшел төскә буяп куйдылар. Әнә хәзер Түбән Норлат авылы картлары да көн саен участок ишеге төбен таптыйлар: буяу кирәк, төсе дә, сыйфаты да югары норлатлылар алганныкы кебек булсын.

Көнбагыш майларын әйт тагын. Участок кызлары базарга сәүдә итәргә чыккан көнне «базарчыларның» кәефләре кырыла: халык майның Норлатта җитештерелгәнен кулай күрә: үзе сап - сары, үзе тәмле, өстәвенә бәясе дә арзан: 1 литры 6 мең сум гына тора. Узган сезонда (сезон октябрьдән апрельгәчә дәвам итә) җитештерелгән 108 тонна көнбагыш маеның тулысынча сатылып бетәчәгенә ышанычлары зур нефтьчеләрнең. Шуның 15 проценты, ягъни 65 тоннасы килешүдә каралганча көнбагыш китерүчеләргә бирелде. 43 тоннасы кибетләр аркылы реализацияләнә. Ә тулаем сезон дәвамында 512 тонна көнбагыш эшкәртелгән. Шулардан әле 259 тонна түп тә чыккан. Ә бу - терлек өчен бәяләп бетергесез ризык. Шуның 40 проценты поставщиклар өлешенә туры килсә шактый ук өлешен үз «Дуслык» ярдәмче хуҗалыкларына калдырганнар. Савым сыерлары рационына аны һәр малга көнгә 500 грамм исәбеннән керткәннәр иде, сөт куерып, артып китте.

Гомумән, участокка көнбагыш тапшыру бик кулай: 1 тонна чималның 25 проценты нигездә чиста май, 60 проценты түп өлешенә туры килә. Маең да, түбең дә, олифың, буявың да була дигән сүз. Киләчәктә татлы ризык - казинаки, хәлвәле дә булып була әле хәтта. Аның беренчесе сынау партияләрендә чыгарылган инде. Җәй моның өчен махсус җиһаз урнаштырылачак, көзгә таба кибеттән нефтьчеләрнең казинакиларын да сатып алу насыйп булыр, мөгаен. Шулай булгач, нефтьчеләр базар шартларына яраклашмыйлар дип кем әйтер икән?

**Р.ГИНЯЕВА.**

## Мунчасы да, мунчасы!..

Сүзем - шәһәр мунчасы турында. Норлатта аны табуы кыен түгел - автовокзал янында гына. Биредә мөдир булып энергияле, аралашучан һәм таләпчән хатын Нина Борисовна Петрова эшли. Мунчаның шикаятьләр һәм тәкъдимнәр кенәгәсендә гел рәхмәт сүзләре генә. Мунчага атнасына уртача 250 кеше йөри. Әле бу мунчага бушлай йөрүче I - II группа инвалидлар, балалар һәм башкаларны санамыйча. Мунчада парекмахерская да бар, озакламый массаж кабинеты һәм буфет та ачыласы. Киләчәктә икенче катта кабиналар булдырырга да планлаштыралар. Төсле телевизор алып та куясылары килә, тик әлегә акча таба алмыйлар.

Биредә 8 кеше эшли. Эшләре һич тә җиңел димәс идем. Аларга тазалык - саулык, эшләрендә уңышлар телисе килә.

**В.КОМОЛОВ.**

## Продукция мул икән...

**Районда ит - сөт җитештерү узган ел белән чагыштырганда күпкә артты. Ит - сөт җитештерүдә яхшы күрсәткечләргә ирешкән хуҗалыклар арасында «Чирмешән» КХАсы да бар. Минем әңгәмәдәшем - хуҗалыкның баш зоотехнигы Р.И.Сиражетдинов.**

***- Районда ит - сөт җитештерүдә соңгы арада зур алга китеш сизелә. Уңышларда «Чирмешән» КХАсы хезмәтчәннәренең дә өлеше бар. Менә шулар хакында сөйләсәгез иде.***

- Эшләр әйбәт бара дияргә була. 1 нче кварталда хуҗалык буенча 3364 центнер сөт, 283 центнер ит җитештердек. Узган елның шул чорында бу күрсәткечләр: сөт 2834, ит - 244 центнер тәшкил иткән иде. Бүгенге көндә уртача көнлек савым 10,7 килограмм. Бу узган елгыдан 2,4 килограммга артык. Сөт буенча беренче урында беренче кат бозаулаган таналар караучы Зөлфия Сиражетдинова. Елның өч аенда һәр сыердан уртача 1152 килограмм сөт савып алды ул. Икенче, өченче урыннарны икенче бригададан Валентина Герасимова белән Вера Романовалар били. Алар сауган сөт 1139 - 1013әр килограмм тәшкил итә, ит җитештерүдә үзләре караган маллардан 710 - 650шәр грамм тәүлеклек артым алып Хөснуллина Нәфилә, Хворостьева Ульяна апалар беренче кварталны уңышлы тәмамладылар.

***- Белүемчә, сез бозауларны салкында үстерүгә районда беренчеләрдән булып керештегез. Бүгенге көнгә аның нәтиҗәләре ничегрәк?***

- Бүгенчесе көндә бездә 120 бозау салкын метод белән асрала. Алар көн буе аранда. Бары төнгелеккә генә торакларына кертелә. Үлем - китем салкында үскән бозаулар арасында бөтенләй юк диярлек. Алар таза, көр. Бүген яшь малларны Минталип Кыямов, Кәүсәрия Туктарова, Резидә Зәйнетдинова карыйлар. Тәүлеклек артым 700 - 780шәр грамм тәшкил итә. Бу күрсәткечләр узган елгыдан 150 - 250 граммга артык.

***- Менә кышлатуның да соңгы этабына кердегез. Азык запасыгыз терлекләр көтүлеккә чыкканчы җитәме?***

- Азык бөтен төрләре буенча да җитәрлек. Инде терлекләрне җәйләүгә күчерү буенча әзерлек эшләре күрә башладык. Бигрәк тә икенче бригаданың җәйге тораклары зур ремонт сорый. Кышкы торакларда да савым сыерларын бәйсез асрауга күчерү буенча реконструкцияләр уздырасы бар. Продукция җитештерүне арттыру, мөмкин кадәр аз чыгымнар тоту юлы белән аның үзкыйммәтен киметү безнең төп максат. Продукция мул булса - без дә бай яшәрбез.

**Әңгәмәдәш - Ж.ШАКИРОВ.**

## Чебешне... яз көнне саныйлар

**Мамык инкубатор станциясе** - быелгы сезонда 240 мең чеби чыгарып халыкка реализацияләргә тиеш. Финанс - акча кыенлыгы үзен сиздерсә дә коллектив үз алдына куелган бурычны тулысынча хәл итәргә тырыша. 15 апрельгә 160 мең йомырка махсус шкафларга чеби чыгарырга урнаштырылган булса, аның 70 меңнән артыгы исән - сау борын төртеп, халыкка сатылды инде. Чебиләрнең бройлер, ит - күкәй юнәлешендәгеләрен сайлап алырга мөмкин биредә. Чималны нигездә Тукай районы һәм Яр Чаллы шәһәрләре кошчылык фабрикаларыннан алып кайталар. Бригадир Лидия Михайловна Гаращенко кул астында кызлар эшне технологик таләпләр нигезендә, җиренә җиткереп башкарырга тырышалар. Сүз уңаеннан, Лидия Михайловна бу хезмәттә 13 елдан артык эшли инде, аны нечкәлекләренә кадәр белә. Хәзер, пенсия яшендә булса да, коллективтан китәргә уйламый. Хәер, кошчылар үзләре дә бригадирларыннан аерылырга теләмиләр әле. Оператор Татьяна Алексеевна Соболева, Татьяна Павловна Лялькова ничә ел аның янәшәсендә эшлиләр, хезмәткә аңардан өйрәнделәр бит. Яшь оператор Надежда Павловна да өлкәннәр янәшәсендә үзен ышанычлы хис итә. Барлык җиһазларның төзеклеге исә механик - электрик Олег Кириллович Кирилловтан тора. Тырыш, булдыклы механик үз бурычын шулай ук намус белән үти.

Станциядә чебиләрне үстереп сату цехы да бар, теләүчеләр кошларның инде тернәкләнгәнен дә сатып ала алалар. Цехта эшләүче яшь эшчеләр аларны җиренә җиткереп, сабый бала карагандай тәрбиялиләр.

- Чеби алырга теләүчеләр кайсы көнне килсәләр дә буш китмәячәкләр, теләгән юнәлештәгесен сайлап ала алалар,- ди Лидия Михайловна Гаращенко. - Коллективның заманында 510 мең данә чеби чыгарып саткан чаклары бар иде. Хәзерге чор өчен гамәлдәге план да кызлардан зур тырышлык сорый,- дип өсти бригадир.

Инкубаторлык - кошчылык станциясе кызларына бу яктан тел - теш тидерерлек түгел. Шуңа да алар язгы һәр көндә яңа чебиләр саныйлар.

**С.НУРУЛЛИНА.**

